**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИШНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

КАРАР

2018 елның 24 сентябре №192

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында»гы 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 22, 56 статьялары белән, «Җирле референдум турында»гы 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 13 статьясы, «Җирле референдум уздыруны инициативалау турында»гы Бишнә авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 сентябрендәге 190 номерлы карары нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге Советы Карар кабул итте:

1. 2018 елның 18 ноябренә Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны расларга:

"Сез 2019 елда үзара салым акчаларын

Бишнә авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен юнәлтү кертүгә ризамы:

2.1 янгын гидрантларын урнаштыру;

2.2 смета документларын әзерләү, төзелеш контролен тормышка ашыру.

"ӘЙЕ "" ЮК.».

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Зеленодольск муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук Бишнә авыл җирлеге мәгълүмат стендларында түбәндәге адресларда: Бишнә авылы, Үзәк урам, 5 йорт (җирлек администрациясе бинасы), Мәктәп урамы, 10 йорт( авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга .

**Бишнә авыл җирлеге**
**башлыгы, Совет рәисе** **И.М.Фатхуллин**